ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594
Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Морквашы авылы, 422594
Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.10.2023 — 2

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Набережные Моркваши

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы гражданнары арасында 2023 елның 10 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
   - Урман Морквашы авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Урман Морквашы авылы, Үзәк урамы, 24 нче йорт адресы буенча 11.00 сәгатьтә гражданнар җыенын уздырырга.
4. Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гаязов